РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Сарлинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 68А, Азнакаевский
район, с.Сарлы, 423315,
тел./факс (885592)36-5-34
E-mail: Sarl.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Сарлы авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 68 А йорт, Азнакай районы,
Сарлы авылы, 423315
тел./факс (885592)36-5-34
E-mail: Sarl.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**от «27» ноябрь, 2023 ел** **№3**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Сарлы авылында 2024 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын ТР, Азнакай муниципаль районы, Сарлы авылы, Үзәк ур., 68А адресы буенча урнашкан Сарлы авылындагы КФҮ бинасында 2023 елның 7 декабрендә 13.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2023 елның 27 ноябреннән дә соңга калмыйча, гражданнарга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Башкарма комитетында халык җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын түбәндәге адрес буенча тәэмин итәргә: Сарлы авылы, Үзәк урам, 68а йорт;

- сайлау хокукы булган Сарлы торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Сарлы торак пункты халкына халык җыены турында хәбәр итәргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2024 елда Сарлы авыл җирлеге Сарлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, ветераннарыннан,

Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан, һәм гаилә әгъзасы махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән гаиләләрдән тыш, 1000 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 500 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү автомобиле йөртүчесенең хезмәтенә түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге (Сарлыда юл ремонтына вак таш сатып алу);

- Бәйрәм чараларын оештыру өчен шартлар тудыру һәм бәйрәм чараларын уздыру (чараларны уздыру өчен аппаратура алу);

- Авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру (балалар өчен уен аттракционнары сатып алу, МТЗ-82 өчен асылмалы җиһазлар сатып алу (ботак турагыч, чапкыч)?

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Сарлы авылы, Үзәк урамы, 68А адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында,

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http//aznakayevo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык Л.М.Хаҗиев